**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станция Высокая Гора,
Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Кооперативная ур, 5, Биектау т/ю станциясе поселогы,
Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-61, факс: 2-30-86, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**
**от 26.06.2020** **№ 507**

## "Күчемсез милек үзәге" муниципаль унитар предприятиесенең банкротлыкны кисәтү һәм түләү сәләтен торгызу максатларында финанс ярдәме күрсәтүгә субсидия бирү Тәртибен раслау турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 78 статьясы, 2002 елның 26 октябрендәге 127-ФЗ номерлы «Бөлгенлек (банкротлык) турында»гы Федераль законның 30, 31 статьялары, 2002 елның 14 ноябрендәге 161-ФЗ номерлы «Дәүләт һәм муниципаль унитар предприятиеләр турында» Федераль закон, 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль закон, «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, «Күчемсез милек үзәге» муниципаль унитар предприятиесенең банкротлыкны кисәтү һәм түләү сәләтен торгызу максатларында, Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. «Күчемсез милек үзәге» муниципаль унитар предприятиесенең банкротлыкны кисәтү һәм түләү сәләтен торгызу максатларында финанс ярдәме күрсәтүгә субсидия бирү Тәртибен кушымта нигезендә расларга.
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).
3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан вакыттан үз көченә керә.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Биектау муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе Д.Ф. Шәйдуллин

Кушымта
Расланды
Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның ____________ №_________
Карары белән

# "КҮЧЕМСЕЗ МИЛЕК ҮЗӘГЕ" МУНИЦИПАЛЬ УНИТАР ПРЕДПРИЯТИЕСЕНЕҢ БАНКРОТЛЫКНЫ КИСӘТҮ ҺӘМ ТҮЛӘҮ СӘЛӘТЕН ТОРГЫЗУ МАКСАТЛАРЫНДА ФИНАНС ЯРДӘМЕ КҮРСӘТҮГӘ СУБСИДИЯ БИРҮ ТӘРТИБЕ

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге тәртип (алга таба - Тәртип) Россия Федерациясе Бюджет кодексының 78 статьясы, 2002 елның 26 октябрендәге 127-ФЗ номерлы «Бөлгенлек (банкротлык) турында» Федераль законның 30, 31 статьялары нигезендә эшләнгән һәм «Күчемсез милек үзәге» муниципаль унитар предприятиесенең банкротлыкны кисәтү һәм түләү сәләтен торгызу максатларында финанс ярдәме күрсәтүгә субсидия бирү максатларын, шартларын һәм тәртибен контрольдә тоту тәртибен билгели (алга таба – субсидия), субсидия бирүне туктату нигезләрен үтәүне, шулай ук аны биргәндә билгеләнгән шартларны бозган очракта, субсидияне кире кайтару тәртибен билгели.

1.2. Субсидияләр «Күчемсез милек үзәге» муниципаль унитар предприятиесенең (алга таба - Субсидияләр алучы) түләү сәләтен торгызу һәм муниципаль берәмлекнең муниципаль милкен түләүсез һәм кире кайтарылмый торган нигездә саклап калу максатында бирелә.

1.3. «Күчемсез милек үзәге» МУПнә субсидия чираттагы финанс елы башына Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы бюджетында каралган акчалар исәбеннән, бюджет турындагы законга (карарга) тиешле бюджет ассигнованиеләрен кертү шарты белән яисә агымдагы финанс елында бюджет турындагы законга (карарга) тиешле үзгәрешләр керткәннән соң бюджетка өстәмә кертемнәр тиешле чыганаклары булганда, һәм (яисә) бюджет чыгымнарының аерым статьялары буенча бюджет ассигнованиеләрен кыскартканда бирелә.

1.4. Субсидияләр Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы бюджеты акчалары исәбеннән бушлай һәм кире кайтарылмый торган нигездә «Күчемсез милек үзәге» муниципаль унитар предприятиесенең банкротлыкны кисәтү һәм түләү сәләтен торгызу максатларында финанс ярдәме күрсәтүгә субсидия бирү турындагы Вәкаләтле орган һәм Субсидия алучы арасында төзелә торган килешү (алга таба - шартнамә) нигезендә бирелә.

1.5. Әлеге Тәртип нигезендә субсидия формасында Субсидия алучыга бирелә торган район бюджеты акчалары, максатчан билгеләнешкә ия.

## 2. Субсидия бирүнең максаты һәм шартлары

2.1. Финанс ярдәме күрсәтүгә субсидияләр «Күчемсез милек үзәге» МУПның банкротлыкны кисәтү һәм түләү сәләтен торгызу максатларында Биектау муниципаль районы бюджетында каралган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә бирелә.

2.2. «Күчемсез милек үзәге» МУПнә субсидия бирү шартлары булып, 2002 елның 26 октябрендәге 127-ФЗ номерлы «Бөлгенлек (банкротлык) турында» Федераль законның 3 статьясының 2 пунктында билгеләнгән, Гамәлгә куючы, милекче тарафыннан акчалата йөкләмәләрне түләү, мәҗбүри түләүләр һәм бурычлының түләү сәләтен торгызу өчен җитәрлек күләмдә финанс ярдәме бирүне таләп итә торган банкротлык билгеләре тора.

2.3. Субсидия алучыга субсидияләр бирүнең мәҗбүри шарты булып Вәкаләтле орган һәм муниципаль финанс контроле органы тарафыннан Субсидия бирүнең шартлары, максатлары һәм тәртибе үтәлешен тикшерүләрне мәҗбүри тәртиптә гамәлгә ашыруны күздә тотучы субсидия бирүгә Вәкаләтле орган белән төзелгән килешү тора.